**ГЛАВА РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631д.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел (факс): 8 84378 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 8 84378 4-74-98

---

**2024 елның 07 ноябре** **7 номер**

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегенең Сингели торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

2024 елның 19 ноябрендә 14.00 сәгатькә Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегенең Сингели торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1. 2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Сингели торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, төзекләндерү;

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Рождествено авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М. Гуцу**